**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы структурасына үзгәреш кертү турында**

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы структурасын камилләштерү максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы структурасын раслау турында» 2011 елның 24 февралендәге ПУ-79 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 3 ноябрендәге ПУ-915 номерлы, 2013 елның 30 ноябрендәге ПУ-1169 номерлы, 2015 елның 25 мартындагы ПУ-368 номерлы, 2017 елның 26 маендагы ПУ-442 номерлы, 2019 елның 11 ноябрендәге ПУ-670 номерлы һәм 2021 елның 29 маендагы ПУ-413 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы структурасына, аны кушымтада бирелүче яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 25 август
№ ПУ-669

Татарстан Республикасы
Президентының
2021 елның «25» августындагы
ПУ-669 номерлы Указына
кушымта

## Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы структурасы

